КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 12 апрель г.Казань № 280

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясенә субсидия бирү тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган оешмасына субсидия бирү тәртибен раслау турында» 2014 ел, 29 август, 624 нче карары үз көчен югалткан дип санау хакында» 2015 ел, 11 июнь, 427 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 17 май, 321 нче; 2016 ел, 9 июль, 465 нче; 2016 ел, 2 сентябрь, 610 нчы; 2017 ел, 24 август, 598 нче; 2018 ел, 11 апрель, 447 карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

преамбулада «2020» саннарын «2021» саннарына алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган «Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү фонды» коммерциягә карамаган микрокредит компаниясе чыгымнарын финанс тәэмин итүгә (каплауга) Татарстан Республикасы бюджеты исәбеннән субсидия бирү тәртибендә:

1 пунктта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Субсидия Фондка түбәндәге максатларда бирелә:

Татарстан Республикасының эшмәкәрлеккә булышлык күрсәтү үзәгенең эшчәнлеген тәэмин итү;

социаль өлкәдә Инновацияләр үзәге эшчәнлеген тәэмин итү;

яшьләр эшмәкәрлегенә ярдәм күрсәтү һәм аны үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына мәгълүмати ярдәм күрсәтү һәм үз бизнесыңны төзүне популярлаштыру буенча кампания оештыру;

«Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына финанс ярдәме күрсәтү» дәүләт мәгълүмат-аналитика системасын төзү һәм кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына ярдәм күрсәтү чаралары нәтиҗәлелеген мониторинглау;

кече һәм урта эшмәкәрлек субъектлары өчен хезмәтләр күрсәтү оештырыла торган бизнес өчен дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү күп функцияле үзәкләрен төзү һәм үстерү;

Бизнес-инкубация һәм кластер үсеше үзәген үстерү;

микрозаемнар бирү механизмнарын үстерү;

«Минем бизнес» үзәкләрендә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына хезмәт күрсәтү комплексы, сервислар һәм ярдәм чаралары күрсәтү;

моношәһәрләрдә кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының тизләтелгән үсеше өчен дәүләт микрофинанс оешмасын үстерү;

кече һәм урта эшмәкәрлекнең экспорт юнәлешле субъектларына ярдәм күрсәтүне координацияләү үзәген үстерү;

һәр максатчан төркем өчен эшмәкәрлек эшчәнлегенә җәлеп итү һәм үз бизнесларын булдыруга ярдәм итү чараларын гамәлгә ашыру, шул исәптән яшь эшмәкәрләр бергәлеге булдыруга ярдәм итү һәм остазлык институтын үстерү.»;

3 пунктта «2020» саннарын «2021» саннарына алыштырырга;

3.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.1. Фондка бирелә торган субсидия күләме Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына кушымта нигезендә билгеләнә.»;

4 пунктка түбәндәге эчтәлекле 44 пунктча өстәргә:

«44. Әлеге Тәртип нигезендә бирелә торган бюджет акчаларын төп бүлүче булып Вәкаләтле орган тора.»;

5 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Субсидия бирүнең нәтиҗәлелек күрсәткечләре (максатчан күрсәткечләре) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 октябрь, 823 нче карары белән расланган «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасының икътисадый үсеше һәм инновацион икътисады» дәүләт программасының «2018 – 2021 елларга Татарстан Республикасында кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерү» ярдәмче программасына кушымта нигезендә билгеләнә Килешүдә күздә тотыла.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин